ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО АЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ИБЫНДАГЫПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» 07 2023г. №23

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) тикшерү комиссиясе составын һәм Нигезләмәсен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балалар уен мәйданчыкларын җиһазлау һәм аларның өслеге» ГОСТ Р. 52301-2013 Файдаланганда куркынычсызлык. Гомуми таләпләр.” нигезендә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, балаларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау, гражданнарның уңайлы һәм куркынычсыз яшәвен тәэмин итү, балалар уен мәйданчыкларын төзекләндерү объектларының, җиһазлау һәм өслекләре сакланышын тәэмин итү, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) эксплуатацияләүнең иминлеге максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) тикшерү буенча комиссия төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) тикшерү комиссиясе составын (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) тикшерү комиссиясе турында нигезләмәне (2 нче номерлы кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров

1 нче номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитетының
«11» 07 2023 ел №23
карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) тикшерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | А.Н. Захаров - Урыссу ш.т.п. Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| Комиссия секретаре: | Т.Г. Исмәгыйлева - Урыссу ш.т.п. Башкарма комитетның әйдәп баручы белгече |
| Комиссия әгъзалары: | |
| | Д.В. Чесноков - "Удача" ТМШ рәисе (килешү буенча) |
| | Р.М. Канзафаров - «Восток» ТМШ рәисе (килешү буенча) |
| | Г.Т. Абдуллина - «Ютазы районы идарәче компаниясе» ҖЧҖ идарәчесе (килешү буенча) |
| | Э.Ж. Гаипов - "Төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча Урыссу предприятиесе" МУП директоры (килешү буенча) |
| | Г.А. Латыйпова - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы (килешү буенча) |

2 номерлы кушымта
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитетының
«11» 07 2023 ел №23
карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды мәйданчыкларын) тикшерү комиссиясе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан муниципаль балалар мәйданчыкларын (уен, спорт, ишегалды) тикшерү буенча Комиссия (алга таба - комиссия) балалар мәйданчыкларында (уен, спорт, ишегалды) балалар һәм яшүсмерләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә имгәнү, авыр нәтиҗәләр китереп чыгаручы сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә, куркынычсызлык буенча контрольне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшләр башкару, эксплуатация, шулай ук уен җиһазларының куркынычсызлык таләпләренә туры килүен бәяләү максатында төзелә.

1.2. Комиссия үз эшендә әлеге Нигезләмәгә, барлык төр җиһазларны монтажлаганда һәм эксплуатацияләгәндә куркынычсызлыкның гомуми таләпләрен билгеле торган норматив документларга таяна.

1.3. Комиссия Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларының (уен, спорт, ишегалды) җиһазларын тикшерә.

2. Комиссиянең бурычлары

2.1. Комиссиянең бурычлары булып тора:

2.1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларында (уен, спорт, ишегалды) дәүләт стандартлары үтәлешенә, куркынычсызлыкның төп таләпләрен исәпкә алып, тикшерүләр үткәрү.

2.1.2. Балаларның һәм яшүсмерләрнең тормышында һәм сәламәтлегендә үлемгә, имгәнүгә, авыр нәтиҗәләргә китерү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

3. Комиссиянең вәкаләтләре

3.1. Комиссия уен җиһазларына комплексны тикшерү уздыра (аның техник халәтен, конструкциянең бөтенлеген, эретеп ябыштыру җөйләренең торышын,

беркетү һәм беркетелгән детальләрнең торышын, өслекләрнең сыйфатын, габаритлы үлчәмнәрне һәм тышкы күренешне тикшерү).

Комиссиянең составы һәм аны төзү тәртибе

4.1. Комиссия, Комиссия рәисе, секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

4.2. Комиссия әгъзалары комиссия эшчәнлегенә кагылышлы документлар һәм материаллар белән таныша ала.

5. Комиссия эшен оештыру

5.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларына (уен, спорт, ишегалды) функциональ тикшерү уздыру. Функциональ тикшерү эш торышын, җиһазларның искерү дәрәҗәсен, ныклыгын һәм тотрыклылыгын бәяләү максатында җентекле тикшерү булып тора.

Тикшерүне 3 айга бер тапкыр булган вакыт дәвамлылыгында үткәрәләр.

Функциональ тикшерү уздырганда, түбәндәгеләр билгеләнә:

- балалар мәйданчыгының һәм җиһазлар өслегенең чисталыгы һәм тышкы күренеше (уен, спорт, ишегалды);
- җиһазлар өлешләреннән уен мәйданчыгы өслегенә кадәр ераклыкларны саклау;
- чыгып торган фундаментлар өлешләре булу;
- җиһазлар элементларының дефектлары/төзексезлеге булу;
- җиһазларның детальләре булмау;
- җиһазларның хәрәкәтле өлешләренең кирәгеннән артык тузганлыгы;
- җиһазларның структур бөтенлеге.

5.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урнашкан балалар мәйданчыкларының (уен, спорт, ишегалды) җиһазларын ел саен төп карап чыгуны уздыру.

Ел саен төп тикшерүне куркынычсызлык җиһазларының техник торышын бәяләү өчен елына кимендә бер тапкыр вакыт аралыгында үткәрәләр.

Ел саен тикшерү барышында түбәндәгеләрне билгелиләр:

- агач элементларның черегән булуы;
- металл элементларның коррозиясе булу;
- башкарылган ремонт эшләренең җиһазлар иминлегенә йогынтысы.

Җиһазларның яшерен, авыр үтеп керә алырлык элементларына аерым игътибар бирәләр.

5.3. Тикшерү тәмамлангач, Комиссия балалар мәйданчыгы (уен, спорт, ишегалды) җиһазларын тикшерү һәм тикшерү актын әзерли, анда тиешле чаралар күрү максатыннан, Россия Федерациясенең техник җайга салу өлкәсендәге закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларына туры килү (туры килмәү) турында нигезле нәтиҗәләр булырга тиеш, шулай ук тиешле язмаларны тикшерү журналына кертә.

5.4. Комиссия кабул иткән бәяләмә белән килешмәгән комиссия әгъзалары язма рәвештә үзләренең аерым фикерен бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия бәяләмәсенә кушымта итеп бирелә.

5.5. Комиссия карарлар кабул итү өчен билгеләнгән компетенция чикләрендә һәм гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы була.